| | | |
|---|---|---|
| **КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 11 май № 294

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары аппаратлары структурасы һәм штат расписаниесен раслау турында» 2007 ел, 12 ноябрь, 626 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының җәмәгать судьялары аппаратлары структурасын һәм штат расписаниесен раслау турында» 2007 ел, 12 ноябрь, 626 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 21 декабрь, 738 нче; 2010 ел, 29 ноябрь, 957 нче; 2013 ел, 9 август, 556 нчы; 2013 ел, 11 декабрь, 976 нчы, 2014 ел, 17 март, 163 нче, 2016 ел, 14 гыйнвар, 11 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. 2016 елның 1 маеннан Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары аппаратлары хезмәткәрләренең штат санын вазыйфаи окладлар, тариф ставкалары буенча 2 753,71 мең сум күләмендәге айлык хезмәт өчен түләү фонды белән 725,5 берәмлек итеп билгеләргә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары аппаратларының штат расписаниесен бу карарга теркәлгән кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2007 ел, 12 ноябрь, 626 нчы
карар белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 11 май, 294 нче
карары редакциясендә)

**Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары аппаратларының штате расписаниесе**

| **Вазыйфа исеме** | **Саны, берәмлек** | **Вазыйфаи оклад, тариф ставкасы, сум** | **Хезмәткә түләүнең айлык фонды, тариф фонды, сум** |
|---|---|---|---|
| Консультант | 141 | 4 448,0 | 627 168,0 |
| Суд утырышы секретаре | 188 | 4 448,0 | 836 224,0 |
| 2 разрядлы өлкән белгеч – занцелярия мөдире | 123 | 3 554,0 | 437 142,0 |
| 2 разрядлы белгеч | 173 | 3 343,0 | 578 339,0 |
| **Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте хезмәткәрләрен** | **625** | | **2 478 873,0** |
| Өлкән белгеч | 14 | 4 899,0 | 68 586,0 |
| Җиңел автомобиль йөртүче | 2 | 2 839,0 | 5 678,0 |
| Биналарга комплекслы хезмәт күрсәтү һәм ремонт ясау буенча 4 разрядлы эшче | 5 | 2 557,0 | 12 785,0 |
| Биналарга комплекслы хезмәт күрсәтү һәм ремонт ясау буенча 3 разрядлы эшче | 15 | 2 440,0 | 36 600,0 |
| Җитештерү һәм хезмәт урыннарын 2 разрядлы җыештыручы | 64,5 | 2 344,0 | 151 188,0 |
| **Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларына кертелмәгән хезмәткәрләр барысы** | **100,5** | | **274 837,0** |
| Җәмәгать судьялары аппаратлары буенча барлыгы | 725,5 | | 2 753 710,0 |

---